Сослъвэт кӯпэрэ

Сыбызгы

Свисток Whistle



Кадерле балам!
Сиңа Яңа елда яңа бүләк!

Бу елдан синең өеңә "Сыбызгы" да килеп торачак. Әлбәттә, "Салават күпере"нә ияреп. "Сыбызгы" "Салават күпере" журналына язылган баланың кулына сызгыртып килеп керәчәк. Өч айга бер мәртәбә.

Аны "Салават күпере" белән бутамагыз. "Сыбызгы" – аның энесе. "Сыбызгы"га аерым язылып торасы юк!

Кадерле балам! Сиңа тагын бер күчтәнәч!

"Сыбызгы" берьюлы өч телдә чыга. Татар, инглиз һәм рус телләрендә. Ходай теләсә, төрек телен дә өйрәнә алырсың әле...

Ә татар телен бик яхшы өйрәнсәң, башка чит телләрне дә өйрәнә алырсың, иншалла!

Дәү үскәч, зур кеше булырсың, Алла боерса! Космонавтлар кебек галәмгә очарсың! Белеп тор: башка планеталарда бары тик татар телендә генә сөйләшәләр. Чөнки төрки-татар теле бик борынгы тел!

Сәлам белән "Сыбызгы".

Мин бакчага барам

Иртән өлкәннәр эшкә китә. Син дә «эшкә» барасың. Синең «эшең» балалар бакчасында. Балалар бакчасына бару «эш» түгел бит ул, дисеңме? Алай микән?! Әйдә, бергәләшеп уйлап карыйк. Син бакчада калсаң гына әти-әниең эшкә китә ала. «Бакчага бармыйм!» – дип кәҗәләнсәң, әти-әниең дә эшкә бара алмый! Шулай булгач, аларны эшкә җибәреп, син дә «эшлисең» булып чыга.

Ә мин балалар бакчасына йөрмим бит, дисеңме? Бик әйбәт. Димәк, син өлкәннәр белән өйдә генә каласың икән. Әмма әти-әниеңне син дә эшкә җибәрәсең. Шулай булгач, үзең дә «эшлисең» дигән сүз. Афәрин!

Ә хәзер Булат исемле малайның бакчага баруы турында рәсемле хикәят.

© "Сыбызгы" 2008 ел

Сызызгы

Булат бакчага бара


Булат идёт в детский сад

Bulat goes to the kindergarten





САЛАВАТ КҮПЕРЕ



– Кик-ри-кү-үү-үк! – дип кычкырды кызыл кикрикле әтәч. – Бу өйдә ялкаулар юк!
– Ку-ка-ре-ку! – прокричал петух с ярко-красным гребешком. – В этом доме ленивых нет!
– Cock-a-doodle-do! – shouted the Cockerel. – This house has not lazy people!



Инде таң аткан икән, торыр вакыт та җиткән.
Взошла заря, вставать пора.
It's dawned. It's time to wake.



– Үс-үс, ү-ү-үс, улым! – диде Булатка әнисе.
– Расти, расти, малыш! – говорит Булату мама.
– Grow and grow, my son! – said mother to Bulat.




– Дәү булып үс, улым! – диде әтисе.
– Расти большой, сынок! – говорит папа.
– Grow and grow, my son! – said father.




Малай караватын җыештыра.
Мальчик прибирает кровать.
The boy makes the bed.



Булат күнегүләр ясарга кереште.
Булат начал старательно делать зарядку.
Bulat starts to make exercises.



Булат күлмәк кия, төймәләрен каптыра.
Булат одевается, застёгивает пуговицы.
Bulat puts on a shirt and buttoned it.



Аннары битен юа, ә песи карап тора.
Потом моет лицо, а котёнок наблюдает.
Then he washed and a cat looked at him.



Песи, песи, пескәем,
Уеннан һич туймыйсың,
Ник битеңне юмыйсың?
Тычканнарың күрерләр
Һәм үзеңнән көләрләр.

Котик, миленький коток,
Хоть ты ростом и с вершок,
Почему не умываешься?
Почему не прибираешься?
На тебя посмотрят мыши –
Засмеют тебя, увидишь.


Pussy, pussy, dear cat,
Why are you playing all the day?
Why is your face not washed?
You would better wash your face
If you don't mice to laugh at you.



Песи бик тә оялды, битен юа башлады.
Застыдился котик, начал умываться.
The cat shies and starts to wash her face.




Малай урамга чыкты: «Көн шундый матур!»
Вышел на улицу мальчик: «День сегодня прекрасен!»
The boy goes to the street.



Чебиләрне ашатты.
Накормил цыплят.
He fed chickens.



Кәҗәгә су эчерде.
Напоил водой козу.
He gave water to a kid.




Атка печән ашатты.
Лошади дал сена.
He fed a horse with hay.



Күреп алды чыпчыкны.
Увидел маленькую птичку.
He saw a sparrow.




Чыпчык канат җилпеде, аннары телгә килде:
– Хәерле иртә, хәерле иртә.
Птичка крылом помахала и прочирикала:
– Доброе утро! Доброе утро!
Then the sparrow said:
– Good morning, good morning.




Бары ялкау Акбай гына һаман да черем итә.
Лишь ленивый Акбай всё ещё спит.
Only lazy Akbye still dozes.



Акбай моны ишетте һәм шартларга җитеште.
Пёс услышал и возмутился.
Akbye heard it and started to bark.




Булат аны оялтты.
Булат его пристыдил.
Bulat scolded him.




Бакчага кәҗә кергән,
Кәбестәне кимергән.
Ишетмәгән, күрмәгән,
Акбай йоклап симергән.

Заявилась коза в огород.
И капусту к себе тянет в рот.
Акбай всё на свете проспал.
И головы не поднял.


A kid came to the garden
And ate all the cabbage
Saw nothing, heard nothing
Akbye was sleeping.



Кызарынды, бүртенде, Акбайга кыен булды.
Покраснел Акбай, подвёл хозяев.
He went ruddy. It was very difficult for Akbye.



һау-һаулап кәҗә куды.
С громким лаем он козу прогнал.
He banished kids.



Булат бакчага китә, аны әтисе илтә.
Булат пошёл в садик, а папа его проводил.
Bulat lives in a kindergarten, his father seen him.




Инде юлның яртысы, әнә, бакча капкасы, тәрбияче апасы.
Он увидел в воротах детского сада воспитательницу.
It's over there and there is the nurse.



Килеп җитә ул бик тиз.
– Бер, ике, өч, дүрт, биш.
– Раз, два, три, четыре, пять.
В сад явился я опять.
He comes very quickly.
– One, two, three, four, five.



– Исәнмесез! – ди Булат, тәрбияче апа елмаеп килә.
– Здравствуйте! – сказал он улыбающейся воспитательнице.
– Hello! – said Bulat. The nurse came up to him smiling.



Әтисе китеп бара. Булат бакчада кала.
Тут папа уходит. Булат остаётся.
Daddy has left. Bulat stays in the kindergarten,



Ә бакчада – бәбиләр, бик күп, бик күп тәтиләр.
А в садике много детей, много игрушек. И весело здесь!
In the kindergarten were more kids, more quiet kids.



Санның темасы һәм тексты – З.Хөснияр.
Русчага тәрҗемә – Л.Газизова.
Инглизчәгә тәрҗемә – А.Кутузова.
Рәссам – Ф.Муллахмәт.
Оештыру – А.Леронова, М.Гали, В.Нуриев.
Редактор – Л.Лерон.
Компьютер дизайны – М. Кузиева.
Исәп-хисап – Р. Салих.



САЛАВАТ КҮПЕРЕ
журналына (№2, 2008) кушымта

Приложение к журналу «Салават күпере» (№2, 2008)

Редакция адресы: 420012 Казан шәһәре, Мөштәри урамы, 14 нче йорт.
E-mail:: salavatkupere@mail.ru

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды
һәм төсләргә бүленде.

«Идел-Пресс» ААҖ.

Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Производствога бирелде 14.02.2008 ел. Басарга кул куелды 14.02.2008 ел.
Тиражы 11598 данә. Заказ Т-151.